**Азнакай муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Балтач авылы № 93 «02»октябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 2016 елның 01 июненнән 33 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2016 елның 21 октябереннән №39, 2017 елның 19 сентябереннән 63номерлы, 2018 елның 31 гыйнвареннән 83 номерлы, 2019 елның 28 декабереннән 154 номерлы, 2020 елның 08 апреленнән 161 номерлы, 2021 елның 06 октябереннән 36,номерлы, 2023 елның 07 апреленнән 79номерлы, карарлар редакциясендә)

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 345-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Балтач авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыБалтач авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 октябереннән №39номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтачавыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә (2016 елның 21 октябереннән №39, 2017 елның 19 сентябереннән 63номерлы, 2018 елның 31 гыйнвареннән 83 номерлы, 2019 елның 28 декабереннән 154 номерлы, 2020 елның 08 апреленнән 161 номерлы, 2021 елның 06 октябереннән 36,номерлы, 2023 елның 07 апреленнән 79номерлы , карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 бүлекнең 1 пунктында:

а) алтынчы абзацта «, газ бүлү челтәрләре, газ куллану челтәрләре һәм мондый челтәрләр объектлары» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац белән тулыландырырга:

«- газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына карата «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 30.5 статьясында каралган башка шартлар;»;

в) сигезенче, тугызынчы абзацларны тугызынчы, унынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карар 2023 елның 23 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Л.Хәбипов